МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

улица Бебеля, дом 129,
город Чистополь, 422980

«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Бебель урамы, 129 нчы йорт,
Чистай шәһәре, 422980

№ 989 04.12.2018

***Постановление*** ***Карар***

Архитектура һәм шәһәр төзелеше
өлкәсендә муниципаль хезмәтләр
күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү турында

Чистай шәһәр прокуратурасының 26.11.2018 елгы 02-08-02-2018 нче номерлы протестын үтәү йөзеннән, 27.07.2010 елгы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 10.04.2013 елгы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 254 нче карары белән (алга таба-10.04.2013елгы 254 нче карар) расланган торак бинаны яңадан үзгәртүгә һәм (яки) яңадан планлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 10 нчы кушымта);

1.2. Торак бинаны торак булмаган бинага, торак булмаган бинаны торак бинага күчерүгә рөхсәт бирү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 11 нче кушымта);

1.3. Капиталь төзелеш объектларын төзүгә, реконструкцияләүгә рөхсәт бирү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 12 нче кушымта);

1.4.Объектны файдалануга кертүгә рөхсәт бирү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 13 нче кушымта);

1.5. Җир эшләре башкаруга ордер бирү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент (16 нчы кушымта);

1.6.Реклама конструкцияләрен урнаштыруга рөхсәт бирү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 17 нче кушымта);

1.7.Җир участогының шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 19 нчы кушымта);

1.8. Адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент (20нче кушымта);

1.9. Күп фатирлы торак йортның беренче катында урнашкан фатирда балкон (лоджия) төзүне килештерү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 21 нче кушымта);

1.10. Инженерлык челтәре һәм коммуникацияләр трассалары схемаларын килештерү буенча 10.04.2013елгы 254 нче карар белән расланган муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент ( 22 нче кушымта);

1.11. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 10.04.2013 елгы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 254 нче карары белән расланган ана (гаилә) капиталы акчасын җәлеп итеп гамәлгә ашырылучы (24нче кушымта) ИЖС объектларын төзү (реконструкцияләү) буенча төп эшләрне үтәүне раслаучы документлар бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

1.12. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 27.03.2017 елгы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 223 нче карары белән расланган җирле (муниципаль) билгеләнештәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр үткәрүгә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

1.13. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 27.03.2017 елгы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 224 нче карары белән расланган җирле (муниципаль) билгеләнештәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр үткәрүгә проект документациясен килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

1.14. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 27.03.2017 елгы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 225 нче карары белән расланган җирле (муниципаль) билгеләнештәге мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр үткәрүгә биремнәр бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

1.15. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы башкарма комитетының 24.08.2017 елгы “Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 634 нче карары белән расланган “Капиталь төзелеш объектының архитектура-шәһәр төзелеше күренешен килештерү турындагы карар бирү”гә муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент;

административ регламентның 5 нче бүлегендәге “Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүе”н яңа редакциядә бәян ителәː

5 нче бүлек. “Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазифаи затларының, муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүе тәртибе”

5.1. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерүгә хокукы бар.

Гариза бирүче дәгъва белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә алаː

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаны теркәү срогын бозу;

2) күрсәтелгән очракта муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу.Әлеге очракта гариза бирүченең күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирә ала, әгәр карараларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

3) Гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган документлар яки мәгълүматлар яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

4) Гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар, әлеге Админнистратив регламент белән каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту, әгәр баш тарту сәбәпләре Россия Федерациясенең федераль законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә ( чара

күрмәүләренә) судка кадәрге (судтан тыш) шикаять белдерүе мөмкин, әгәр күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

6) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән каралмаган түләүләр таләп итү;

7) Башкарма комитетның, башкарма комитетның вазифаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән каралган оешманың яки аларның хезмәткәрләренең, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда үзләре җибәргән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуы яисә шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срокларын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә)шикаять бирүе мөмкин, әгәр шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү срогын һәм тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату, әгәр туктату сәбәпләре Россия Федерациясенең федераль законнары һәм алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив-хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар белән карарлмаган булса. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

10) ) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны (аларның булмаулары һәм (яки) дөрес булмаулары) таләп итү яисә 27.07.2010 елгы 210 нчы Федераль законның 7нче маддәсенең 1 өлешенең 4 нче бүлегендә каралган очраклардан кала, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүченең судка кадәрге (судтан тыш) күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять бирүе мөмкин, әгәр карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә)

шикаять белдерелүче күпфункцияле үзәккә 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.3 өлеше белән билгеләнгән тәртиптә тиешле дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрен тулы күләмдә күрсәтү буенча функция йөкләнгән булса.

5.2. Гариза бирүчеләр шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алуга хокуклы.

5.3.Шикаять 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып торучы дәүләт властеның ( җирле үзидарә органы) ачык-хокукый берәмлеге булган тиешле органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне оештыручы), шулай ук 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмаларга язмача формада кәгазьдә һәм электрон формада бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять югарыгы органга ( әгәр ул булса) бирелә яисә ул булмаганда турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. Күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. Күпфункцияле үзәкнең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять күпфункцияле үзәкне оештыручыга яисә Россия Федерациясе субъектларының норматив-хокукый актлары буенча вәкаләте булган вазифаи затка бирелә. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә ( чара күрмәвенә) шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. Күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып, күпфункцияле үзәк, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайты, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлеше белән каралган оешмалар, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәвенә) шикаять почта аша, “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәреннән файдаланып,

әлеге оешмаларның рәсми сайтлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталы яисә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең төбәк порталы аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

. 5.4. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының исеме яки карарлары һәм гамәлләренә (чара күрмәүләре) шикаять белдерелгән муниципаль хезмәткәрнең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы әгәр булса), яшәү урыны турында белешмә, шулай ук элемтә өчен телефон номеры, электрон почта адресы ( әгәр булса) һәм почта адресы (адреслары), алар буенча гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиеш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (чара күрмәүләренә) шикаять белдерү турында белешмә;

4) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазифаи затының яисә муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (чара күрмәүләре) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр. Гариза бирүче үз дәлилләрен рслаучы документлар (алар булганда) яисә аларның күчермәләрен тәкъдим итә ала.

5.5. Әгәр шикаятьне карау өчен әһәмиятле нәрсәләр булган документлар булмаса яки алар шикаятькә беркетелмәгән булса, карар дәлилләрне ( аларны раслаучы документлар тәкъдим ителмәгән) исәпкә алмыйча гына кабул ителә.

5.6 Шикаять муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәк учредителенә, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югарыгы органга ( ул булганда) кергәндә, ул аны теркәгәннән соң унбиш эш көне дәвамында каралырга тиеш, әгәр муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешма гариза бирүчедән доументларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуга шикаять белдерсә яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылу турындагы шикаять булса – аны теркәгәннән соң биш эш көне дәвамында. .

5.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган шикаятьләрне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны юкка чыгару, бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе документларында җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү, гариза бирүчегә акча түләү Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары, Чистай муниципаль районының

муниципаль хокукый актлар белән каралмаган очракта акчаны кире кайтару формасында.

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарталар :

карар кабул иткән көннән соң килә торган икенче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача формада һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьне карау нәтиҗәләре турында сәбәпләр күрсәтелән җавап җибәрелә.

Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылганда, гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күпфункцияле үзәк, 27.07.2010 елда кабул ителгән 210нчы номерлы Федераль законның 16 нчы маддәсенең 1.1 өлешендә каралган оешма башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, бу муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында эшләнә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт алу максатында нәрсә эшләргә тиешлеге турында мәгълүмат бирелә.

Шикаятьне канәгатьләндерү мөмкин түгел дип табылганда, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карау барышында яисә аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки вазифаи затның,шикаятьне карау буенча вәкаләте булган хезмәткәрнең җинаять кылу билгеләре ачыкланса, булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына җибәрәләр.

2. «ГиИР» МБУның әлеге карарын ТРның хокукый-мәгълүматлар рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны үтәүгә контрольлек итүне Чистай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.Ф.Рәхимовка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов